ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

15.06.2020 — № 488

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2021 елларга Алабуга муниципаль районының мәдәният үсеше» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 29 декабрендәге 1491 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм Алабуга муниципаль районында мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2021 елларга Алабуга муниципаль районының мәдәният үсеше» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 29 декабрендәге 1491 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендәге «2017-2021 елларга Алабуга муниципаль районының мәдәният үсеше» сүзләрен «2017-2022 елларга Алабуга муниципаль районының мәдәният үсеше» сүзләренә алыштырырга.

2. «2017-2022 елларга Алабуга муниципаль районының мәдәният үсеше» муниципаль программасын яңа бирелгән редакциядә расларга.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге максатларга билгеләнгән тәртиптә һәм җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә программаны финанслауны тәкъдим итәргә

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Ягудинага йөкләргә.

Җитәкче — Р.М. Нуриев